| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЗЕЛЕНОРОЩИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>«ЗЕЛЕНАЯ РОЩА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 17 марты № 4

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зеленая Роща авыл җирлеге Советының 2013 елның 28 октябрендәге 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зеленая Роща авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 6 декабрендәге 408-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленая Роща авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленая Роща авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зеленая Роща авыл җирлеге Советының 2013 елның 28 октябрендәге 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зеленая Роща вып җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1 статьяны** түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:
«блокланган төзелеш йорты - башка торак йорт (башка торак йортлар) белән бер рәттә гомуми ян стенасы (гомуми як стеналары) белән блокланган һәм җир кишәрлегенә аерым чыгу урыны булган торак йорт.»;

**22 статьяның 2 өлешенең 6 абзацын** «,шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 11 өлешендә күрсәтелгән очракта;» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Зеленая Роща авылы, Төзелеш ур., 1 йорт, Мингәрәев исемендәге АКЦ бинасы, Спиридоновка авылы, Совет урамы, 32 нче йорт Спиридоновка авыл клубы бинасы адресы буенча

урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Зеленая Роща җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе

А.А.Потапов